**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**12.05.2023** **№ 580**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 23 маендагы 509 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2022 елның 01 мартындагы 34 – ОД номерлы «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы халкын сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин ителеш нормативларын раслау турында» 2016 елның 07 октябрендәге 259 – ОД номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» боерыгын үтәү КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 23 маендагы 509 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукының башлангыч (минималь) бәясен билгеләү методикасын (5 нче кушымта) әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.2. Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Биектау муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга аукцион уздыру буенча комиссия составына (6 нчы кушымта) үзгәрешләр кертергә:

1.2.1. Комиссия секретаре Низамиева Гөлнара Мәлик кызын – Биектау муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгечен комиссия составыннан чыгарырга;

1.2.2. Адиярова Ләйсән Хәйдәр кызын – Биектау муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгечен комиссия составына кертергә һәм комиссия секретаре итеп билгеләп куярга;

1.2.3. Комиссия әгъзасы Хөснетдинов Артур Мифтахетдин улын - Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгын комиссия составыннан чыгарырга;

1.2.4. Тарасова Алина Сергеевнаны - Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы вазифаларын башкаручысын комиссия составына кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы сайтына: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М. Р. Булгаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 12 маенда 580 номерлы карары белән расланды

**Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясен билгеләү методикасы**

1. Әлеге методика стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга хокукның башлангыч (минималь) бәясен билгеләү максатларында эшләнде (алга таба - лот).

2. Электрон аукционга куела торган лотның башлангыч (минималь) бәясе астында вәкаләтле орган лотны сатарга әзер булган минималь бәясе аңлашыла.

3. Лотның башлангыч (минималь) бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

НЦЛ = (Спкс х Кп х Sоб) / 365 * Нвр (сум), монда

НЦЛ - Лотның башлангыч бәясе (сум);

Спкс - стационар булмаган сәүдә объекты мәйданы буенча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең уртача күрсәткече (сум);

Кп - стационар булмаган сәүдә объектлары өчен кулланыла торган коэффициент (гомуми мәйданы 200 кв. м. булган стационар булмаган җәмәгать туклануы объектлары өчен Кп 30 га тигез итеп кабул итәргә, стационар булмаган сәүдә объектларының калган категорияләре өчен – 40 ка тигез итеп);

Sоб - стационар булмаган сәүдә объектының мәйданы (кв. м);

Нвр - эшчәнлекнең һәр төре өчен билгеләнгән стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру норматив вакыты.